ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**14.01.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 21**

«Зеленодольск шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 31 мартындагы 729 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (2019 елның 11 июнендәге 1243 номерлы үзгәрешләре белән)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Акционер җәмгыятьләр турында» 1995 елның 26 декабрендәге 208-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җаваплылык чикләнгән җәмгыятьләр турында» 1998 елның 8 февралендәге 14-ФЗ номерлы Федераль закон, « Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1 «Зеленодольск шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 31 мартындагы 729 номерлы карары белән расланган, «Зеленодольск шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру хокукы

өчен аукционны оештыру һәм үткәрү турындагы нигезләмә»гә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 4.5 пунктының җиденче абзацында «мөрәҗәгать итүченең таныкланган мөһере» сүзләреннән соң «(мөһер булу турындагы белешмәләр җәмгыять уставында булса)» сүзләрен өстәргә.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 31 мартындагы 729 номерлы карарының 1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам

Җитәкченең беренче урынбасары А.В. Старостин